| СОВЕТ<br>КУГЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КҮГӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2024 елның 22 ноябре** **№ 179**

Күгәй авылы

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 174 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында (Күгәй авыл җирлеге Советының 2020 елның 12 ноябрендәге 12 номерлы, 2023 елның 16 октябрендәге 131 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 12 июлендәге 176-ФЗ номерлы Федераль закон (2024 елның 29 октябрендәге редакциядә), Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Күгәй авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җир салымы түләү ставкалары, тәртибе турында» 2019 елның 1 ноябрендәге 174 номерлы Күгәй авыл җирлеге Советы карарына (Күгәй авыл җирлеге Советының 2020 елның 12 ноябрендәге 12 номерлы, 2023 елның 16 октябрендәге 131 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2) торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3%, әлеге абзацта күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланыла торган җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган җир кишәрлекләреннән тыш;»;.

1.2. 1.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.3) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм аерым Россия Федерациясе актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль

законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата 0,3% һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артыграк булган җир кишәрлекләреннән тыш".

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук түбәндәге адрес буенча мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урам, 29 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Күгәй авылы, Тынычлык ур., 20 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссия рәисенә йөкләргә.

Күгәй авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф.Х.Хисәметдинова